**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.08.2024 № 926

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2022 елның 07 ноябрендәге 1209 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 07 ноябрендәге 1209 номерлы карары белән расланган 2023-2025 елларга Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына (кертелгән үзгәрешләр белән 13.07.2023 № 703, 28.07.2023 №781, 13.11.2023 № 1438, 14.02.2024 №174) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «2025 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре» III бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшнең күләме |
|---|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | мең кв.метр | 5,603 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү | | 8,830 |
| Электр белән тәэмин итү | мең кв.метр | 2,280 |
| Җылылык белән тәэмин итү | мең кв.метр | 2,143 |
| Су белән тәэмин итү | мең кв.метр | 2,292 |
| Суны агызып җибәрү | мең кв.метр | 2,113 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | мең кв.метр | 9,659 |

| | | |
|---|---|---|
| Подвал бүлмәләрен ремонтлау | мең кв.метр | 0,540 |

- «ресурслар белән тәэмин итү» IV бүлеген, «2025 елда Кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме " IV абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5506480662,88 сум, шул исәптән:

Фондтан – 0,00 сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 10615654,51 сум;

җирле бюджеттан – 11 288 000,00 рубля;

ТМШ, ТК, ТТК әгъзалары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы яки күпфатирлы йортта торак хуҗалары кооперативы – 33745008,37 сум».

- «2025 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга финанс чараларына ихтыяҗ күләме " IV бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сумнарда |
|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | 27922895,79 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү,шул исәптән: | 20130392,00 |
| Электр белән тәэмин итү | 3639733,00 |
| Җылылык белән тәэмин итү | 9835691,00 |
| Су белән тәэмин итү | 2176788,00 |
| Суны агызып җибәрү | 4478180,00 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | 10510399,00 |
| Подвал бүлмәләрен ремонтлау | 450000,00 |
| Проект документациясен эшләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү | 1348704,14 |
| Төзелеш контроле уздыру | 445445,14 |
| БАРЛЫГЫ | 55648662,88 |

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә. К. Габдуллин